Безнең белән үткән мизгелләр күңелегездә мәңге калачак!

# Күкнең җиденче катында



**№ 2**
**ОКТЯБРЬ,2018 нче ел**

*181 нче күп профильле мәктәп*

## Мәктәбебез тормышы

1 октябрь көнне мәктәбебез күләмендә “Өлкәннәр көне” нә багышланган ярминкә булып узды.

5”Е” сыйныфы укучылары ТНВ каналында экскурсиядә булып кайттылар.Журналист һөнәре, репортаж төшерү үзенчәлекләре белән таныштылар. Экскурсия бик җанлы узды.




9”А”,9”Б” сыйныфы укучылары “Компрессормаш”заводында экскурсиядә булып кайттылар.Алар эшче тормышының үзенчәлекле яклары белән танышып, киләчәкләре өчен мәгълүматлар тупладылар.



27 нче октябрь көнне “Бөтен дөнья татарча яза!» акциясе булып узды. Бу көнне 20 илдә,300 ләп мәйданчыкта татарча диктантлар яздырылды. Мәктәбебезнең туган тел укытучылары Насыйбуллина Алсу Илдар кызы, Исмәгыйлева Ләйсән Ринат кызы, Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы да бу акциядә катнашты.






# Безнең уңышлар

Октябрь ае зур уңышларга бай булды.

- Мәктәбебез укучылары бадминтон буенча 2нче урын яулады.
- Районда үткәрелгән “Ел алдынгысы” бәйгесенең “Коллегаларның тануы” номинациясендә Каюмова Ирина 1нче урынга лаек булды.






- Район күләмендә оештырылган “Татар кызы” бәйгесендә Вилданова Алинә 2нче урынны яулады. Афәрин!






# Котлыйбыз!!!

# Туган көнегез белән Сезне!

**Октябрь**





Хөрмәтле укытучыларыбыз!
Подовалов Владимир Васильевич
Горбунова Алевтина Юрьевна
Әминова Камилла Рөстәм кызы
Заһидуллина Лилия Әсфәндияр кызы
Нигъмәтҗанова Руфия Хидият кызы
Сезне чын күңелдән туган
Көнегез белән котлыйбыз, эшегездә зур
уңышлар, бәхетләр, тазалык-саулык,
тынычлык телибез!!!

Хезмәткәрләр күңелендә сездә,
Бары хөрмәт, рәхмәт хисләре;
Гомерегезнең зая узмаганын
Әйтеп тора матур эшләрегез.





# Кызыклы интервью



**Мәктәптә укытучылар гел укучылар янында: сөйләшә, аралаша, белем алалар, фикер алышалар. Гомумән, укытучылар - укучыларның икенче әниләре, дуслары, ярдәмчеләре. Ләкин укучылар укытучылар турында күп нәрсәләрне әле белми. Шул сәбәпле, без –"Яшь хәбәрче" түгәрәге әгъзалары китапханәчедән кызыклы интервью алырга уйладык.**




Исемегез –Мухина Наталья Николаевна

Гаилә хәле –кияүдә.

Мәктәп китапханәсенең эше нидән гыйбарәт- фондны мәктәп программасына туры китереп тулыландыру

Бүгенге көн укучылары нинди китаплар укырга ярата- башлангыч сыйныф укучылары әкиятләр укырга ярата, ә урта һәм өлкән сыйныф укучыларының китап белән кызыксынулары түбән, алар интернет аша мәгълүматны күбрәк интернет аша табалар.

Китапханәнең максаты нинди:Уку һәм тәрбия процессында китап укучыларны яңа информацион алымнар белән тәэмин итү;укучыларда матур әдәбият укуга уңай караш һәм информацион культура тәрбияләү;традицион технологияләрне үстерү, яңа технологияләрне үзләштерү һәм китап укучыларга җиткерү.

Китапханәдә нинди чаралар уздырылды- "Дөрес яшәү үрнәге" кысаларында лекцияләр уздырылды.

Киләчәккә планнарыгыз- китапханә фондын китаплар белән тулыландыру.

Сез китапханәче булып ничә ел эшлисез-2018 нче уку елыннан бирле китапханәче булып эшлим.

Яшьләргә, укучыларга киңәшләрегез: укучыларыбыз китап укудан ямь табарга өйрәнсеннәр, белемнәрен тирәнәйтсеннәр иде.







Китапханәгә килгән соңгы китаплар:



# 24 нче октябрь- Халыкара китап сөючеләр көне

*Китап- кешенең хәтере, юлдашы, киңәшчесе, ярдәмчесе, укытучысы.*
*Китапсыз халык-тарихсыз халыкка әйләнгән, ә тарихын оныткан халыкның киләчәге өзелгән.*
*Кеше китап укудан ямь табарга өйрәнергә тиеш.*
*Әйдәгез, китаплар укыйк, китап сөючеләр булыйк!*
*Әнә, укучыларыбыз да бит китап укырга ярата, шигырь дә чыгарып куялар.....*





*Без мәктәпкә*
*Теләп барабыз.*
*Күп китап укып,*
*Белем алабыз .*

*Туган телем, илем турында ,*
*Яратам мин китап укырга.*
*Куп итеп китап укып,*
*Телим әйбәт кеше булырга .*

*Сәлихҗанов Салават(4 “А” сыйныф укучысы)*



# Укучылар иҗаты



***Инде кыш аена да аяк басарга күп калмады.Беренче кар да явып үтте. Ярата… карны безнең укучыларыбыз. Яратып кына калмыйлар, матур шигырьләр дә иҗат итәләр.Сезгә кайберләрен тәкъдим итәбез.***

Рәхәт булды әле безгә
Кыш быел иртә килде,
боз белән капланды күлебез,
без моңа бик шат инде.
Хоккей уйный башладык без,
Кермичә боз өстеннән
Шулай каты тырышмасаң.
Хоккеист чыкмас бездән.

Мәхмүтова Мәликә( 5 нче сыйныф)



Абыем минем хезмәт итә
Ерак-ерак шәһәрдә,
Өйрәндем инде мин һәр көн
Аңа хатлар язарга.
Ул да миңа хатлар яза
Һәр көнне булмаса да.
Рәхмәт әйтәм хат алганда
Хат ташучы апага


Догамин Рима (5нче сыйныф)

**Куян һәм поши**

- Поши абзый! Хәлең ничек?
Нишләп йөрисен монда?
Шундый зур мөгезең белән
Ник чыктың син юлыма?
- Әй, куянкай, хәлләр начар,
Бу суыкта мин туңам.
Синең кебек сикереп йөрмим
Сикерсәм- мөгезем сына.
-Әй, йомшагым, бирче миңа
Бер уч булса да печән,
Кызган инде, пошикайны
- И зур мөгез, каян алыйм
мин сиңа яшел печән?
Сиңа түгел үземә дә
Кишер юк әле күптән.
Шул арада килде- чыкты
Капчык аскан кыш бабай.
- Әхе-хәй!- диде ул безгә
Ерактан килдем сезгә.
Мин хайваннар яратам
Бүләкләр дә таратам:
Куянга кишер бирәм,
ә пошига күп печән.
Менә шулай, дусларым
Поши бик тә шатланды
Куян ашый башлады,
Яңа ел кызык булды Әхмәтҗанова Рузинә (6нчы сыйныф)







Килеп житте кыш та,
Карлар ява ак күбәләкләр кебек.
Урамнарда буран уйный
Безне куркытырга уйлый
Без курыкмыйбыз,
Саф һавага чыгабыз,
Таудан чана шуабыз,
Кышның буранын куабыз.


Мәхмүтова Мәдинә (5нче сыйныф)

Менә кыш килде,
Урамга чыктык,
Көн жепшек иде
Кар тәгәрәттек.
Марат һәм Айрат
Ясады кыш бабай,
Миләүшә һәм мин
Ясадык Кар кызын.
Аннан соң рәхәтләнеп,
Бергәләп уйнадык,
Шулай һәрвакыт
Булсын татулык.

Хөснетдинова Камилия(5нче сыйныф)

# Тик гомерне ямьсез итеп
# Уздыра күрмә, кеше!

*Безгә тормышта ришвәтчелек сүзе белән бик еш очрашырга туры килә. Конституциядәге*



*законнарга каршы чыгып эшләнгән кайбер гамәлләрне – ришвәтчелек, диләр. Бу турыда телевизор, радиодан гына сөйләп калмыйлар, ә тәрбия сәгатьләре дә уздыралар. Ләкин без әлегә урта сыйныф укучылары гына булгангамы, бу сүзнең чын асылына, мәгънәсенә төшеп җитә алмыйбыз. Ә шулай да миндә бу төшенчә нәфрәт хисен уята.*

*Бүгенге көндә бөтен дөнья буйлап коррупция бик киң таралган. Бөтен нәрсәне диярлек взятка аша алып була: мәктәптәге билгеләрдән башлап, судтагы бик мөһим документларга кадәр. Әлбәттә, закон ягында булган кешеләр коррупциягә каршы каты торалар. Законнан курыкмаган кайбер эшмәкәрләр, мәсәлән, ГБДД эшмәкәрләре взяткаларны алалар. Әгәр дә машина йөртүчеләр тизлекләрен арттырсалар, правалары булмаса, машиналарын дөрес урыннарга куймасалар, взятканы бик теләп бирәләр дә: "Акча бирдем һәм эш бетте",- дип тыныч күңел белән юлын дәвам итәләр. Полициядә следовательләргә дә, судьяларга эшне дәвам иттермәс өчен дә акча бирәләр. Башка үзеннән-үзе шундый сорау туа: Акча дөнья белән идарә итә аламы? Күпләр "әйе" дигән уйдадыр, чөнки нәрсәдер өчен аерым бер күләмдәге акча белән бүләкләү хәзер еш кулланыла, күпләр шунсыз гомер дә итә алмый! Тик андыйларга минем болай дип әйтәсем килә: Ә сәламәтлекне, бәхетне һәм башка бик күп әйберләрне акчага сатып алып буламы? Хәзерге дөньяда бу күп мәгънәгә ия булган нәрсәләр дөнья ваклыклары, милек, байлык үзләштерүгә омтылу белән икенче планга кала түгелме? Миңа калса, яхшы йорт, кыйммәтле машина һәм башка әйберләрне коррупция ярдәмендә җыйган акчага сатып алганчы, үзен тир түгеп тапкан акча ярдәмендә бәхетле гомер итүең мең мәртәбә яхшы түгелме соң?*

*Дөньяда әле тагын шундый очраклар бар: Унберенче сыйныфны тәмамлаучылар югары уку йортларына коррупция ярдәмендә керәләр. Тик ник? Моңа карап алар яхшы укый алырмы соң? Укып бетерсә дә специалист булгач, эшендә яхшы уңышларга ия була алырмы соң? Юк, ул гына да түгел, уку йортын тәмамлый алачакмы? Укый алмаса, өстәмә бер ел шөгыльләнеп яки Бердәм Дәүләт имтиханнарын кабаттан бирү дөресрәк булмасмы? Беренчедән, син үзеңнең хаталарыңны төзәтергә өйрәнәчәксең, икенчедән, белемеңнең дәрәҗәсен көчәйтәсен, өченчедән, коррупциядән котыласын – акчаң яңа кала.*

*Коррупция – миңа кайчакларда зур ташып агучы агулы чишмә кебек тоела. Ташып аккан су шикелле коррупция дә елдан-ел үсә. Бу чишмә суын эчкән кешеләр дә агуланалар. Моның түмен татып карагач, бу җайлы һәм тиз максатка ирешү юлына бик тиз ияләнеп китәләр. Ә шулай да мин яхшыга өметләнәм: Бу "пычрак" чишмәне күмүчеләр табылсын иде.*

*Коррупциянең яхшы якларыннан, начар яклары күбрәк. Ә аны җиңү меңләтә яхшылык китерә. Тик берүзең генә моны башкарып чыга алмавыңа шик юк. "Ил төкерсә, күл булыр", ди татар халык мәкале. Бердәм тотынсак, без моны булдырып чыга алырбыз. Тормыш ул - артык матур, аны менә шундый ваклыклар белән пычратмагыз, аны харап итмәгез. Күңелемә Р.Мингалимнең бер шигырь юлы килә:*

*Тик гомерне ямьсез итеп*
*Уздыра күрмә, кеше.*

*Татар халкы - бердәм, дус халык. Коррупцияне барасы юлыбызда киртә итеп калдырмабыз, аның белән көрәшеп, аңа "Юк!" диярбез, дигән ялкынлы тормыш девиз белән язмамны тәмамлыйм.*

*"Күкнең җиденче катында" түгәрәге әгъзасы язмасы.*

# Укучылар, сезнең өчен! Өйгә эшне ничек эшләргә киңәшләр

***1. Дәрестә актив эшлә: игътибар белән тыңла һәм сорауларга җавап бир.***
***2. Килешмәсәң яисә аңламасаң, сораулар бир.***
***3. Һәр предметтан өйгә бирелгән эшне мөмкин кадәр төгәл итеп, җентекләп язып бар.***
***4. Сүзлекләр һәм белешмәлекләр белән (справочник, энциклопедия һ.б.) эшләргә өйрән. Аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләрен ачыкла, кирәкле фактлар, аңлатмалар, кагыйдәләр, формулаларны эзләп тап.***
***5. Компьютерың булса, аның ярдәмендә кирәкле мәгълүматларны эзләп табарга, электрон таблицалар ярдәмендә төрле исәпләүләр башкарырга өйрән.***



***6. Дәрестә үтелгәннәр авыр кебек тоелса, материалны шул ук көнне кабатла (хәтта киләсе дәрес иртәгә булмаса да).***
***7. Биремнәрне эшләргә керешкәнче, нәрсә эшләргә генә түгел, ә ничек, нинди ысуллар, чаралар ярдәмендә эшләп булганы турында да уйла.***
***8. Ярдәм сорап зурларга яки сыйныфташларыңа, дусларыңа мөрәҗәгать итәргә оялма.***
***9. Дәрес хәзерли башлаганчы, көндәлегеңне ачып кара: барлык биремнәр дә язылганмы?***
***10. Аерым предметлар буенча биремнәрне нинди тәртиптә эшләячәгеңне уйла һәм һәр биремне үтәү өчен күпме вакыт китәчәген чамалап куй.***
***11. Игътибарны җәлеп итәрдәй барлык артык әйберләрне өстәлдән алып куй. Беренче биремне үтәү өчен кирәк булган әсбапларыңны гына калдыр. Эшләп бетергәч, боларын алып куй һәм икенче дәрескә кирәклеләрен әзерлә.***
***12. Дәресләр арасында тәнәфес ясап ал.***
***13. Материалны башта аңларга, аннан соң гына истә калдырырга тырыш.***
***14. Язмача биремнәрне башкарганчы, шуларга караган кагыйдәләрне өйрән.***
***15. Дәреслектәге параграфны укыган вакытта, үз-үзеңә түбәндәге сорауларны бир: текстта кем яки нәрсә турында сүз бара, аның турында нәрсә әйтелә?***
***16. Һәр яңа күренеш яки яңа төшенчәне элек өйрәнгәннәрең белән мәгънә ягыннан бәйләргә тырыш.***
***17. Истә калдырырга тиешле материал зур күләмле һәм авыр булса, аны өлешләргә бүлеп, һәрберсе буенча аерым – аерым эшлә.***
***18. Докладка, сочинение һәм башка төрле иҗади эшләргә әзерлекне соңгы көнгә калдырма, чөнки алар күп вакыт таләп итә. Һәр көнгә авырлыкны тигез бүлеп, берничә көн дәвамында, ягъни алдан әзерлән.***
***19. Телдән бирелгән өй эшләрен эшләгәндә, карта, схемалар куллан, алар сиңа материалны яхшырак аңларга һәм истә калдырырга ярдәм итәрләр.***
***20. Телдән бирәсе җавабыңның планын төзе.***
***21. Белемеңне тикшер.***



---

**Редколлегия: Мәхмүтова Мәдинә**

**Хөснетдинова Камилия**

**Догамин Рима**

**Корчагина Яна**

**Түгәрәк җитәкчесе:А.Ф.Габдуллаҗанова**